**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.06.2020 № 587

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 19 октябрендәге 903 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы территориясе буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутларында халыкка автомобиль транспортында транспорт хезмәте күрсәтүне оештыруга субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләр бирүдән тыш), индивидуаль эшкуарларга, шулай ук физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 06 сентябрендәге 887 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитетының 2018 елның 19 октябрендәге 903 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы территориясе буенча

даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутларында халыкка автомобиль транспортында транспорт хезмәте күрсәтүне оештыруга субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидия алучыга субсидияләр бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

субсидия алучы тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 6 пункты белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы күләмдә бирмәү);

субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмавы.»;

7 пунктта «килешү» сүзеннән соң «(Тәртипкә кушымта)» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм«Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә  Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад мәсьәләләре буенча урынбасары   М.Х.Хабибуллловага йөкләргә

Җитәкче в.б.                                                            Р.И. Галимов